ТАТАРСТАН

РЕСПУБЛИКАСЫ

АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧАЛМАНАРАТ

АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423752, Чалманарат авылы, Үзәк ур., 2 йорт

СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423752, село Чаплманарат ул. Центральная, дом 2



---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 8** **от 10.11.2022**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чалманарат авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзарасалым турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм гражданнарның үзарасалым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 21.09.2022 №647 «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президенты Указы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чалманарат авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чалманарат авыл җирлеге Советы

карар бирэ.

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чалманарат авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибендә расланган,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чалманарат авыл җирлеге Советы тарафыннан 2014 елның 21 мартындагы 4 номерлы, түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезлэмэнен 5.1 пунктына түбәндәге редакциядә абзацны өстәргә:

«Үзара салым акчаларын түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

- Россия Федерациясендә һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар;

- Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр."

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Чалманарат авыл җирлеге башлыгы К.С.Ахметов